Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Данауровка авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре № 9

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 22 ноябрендә 12.30 сәгатькә ДСНТ ВОСТОК гаражы бинасы янында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Галактионово авылы, Үзәк ур., 20А йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

««2021 елда Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең Галактионово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- Галактионово авылында Үзәк урамы буенча сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Данауровка
авыл җирлеге башлыгы В.К. Сәдретдинова